**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«__27_» _____05____ 2026 ел.** **№ __88____**

Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 гыйнварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» карары нигезендә, карар бирә:

1. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 гыйнварындагы 1 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү һәм коткару хезмәтләрен булдыру турында» карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын тәэмин итү турындагы Нигезләмәгә (17.05.2022 №145, 04.08.2022 № 207, 26.04.2024 №86 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4.1 пунктындагы икенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

»Азнакай муниципаль районы халкын мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрдән саклану ысулларын оештыру һәм әзерләү;"

1.2. 4.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“4.2. Мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыга торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итеп:»;

1.3. 4.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

4.6. мобилизация чорында, хәрби хәлнең гамәлдә булу чорында, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркыныч очракларда һәлакәт-коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару буенча:

гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазлау һәм әзерләү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча дәүләт системасының кирәкле көчләрен җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка ашыгыч эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын билгеләү буенча файдалануга даими әзерлектә булдыру һәм ярдәм итү. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру, законнарда билгеләнгән вәкаләтләр кысаларында, Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына Татарстан Республикасының Азнакай янгын-коткару гарнизонына һәм оешмага йөкләнә.»;

1.4. 4.7 пунктындагы беренче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә зыян күргән халыкның тормышын беренче чиратта тәэмин итү буенча:»;

1.5. 4.8 пунктындагы беренче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.8. мобилизация чорында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында килеп чыккан янгыннарга каршы көрәш буенча:»;

1.6. 4.11 пунктындагы беренче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.11. мобилизация чорында барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләр нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында тәртип саклау буенча:»;

1.7. 4.14 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«4.14. Мобилизация чорында, хәрби хәл гамәлдә булган чорда, сугыш вакытында барлыкка килә торган куркынычлар булганда халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның тотрыклы эшләвен тәэмин итү буенча:

икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссияләр төзү һәм аларның эшен оештыру;

икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләре нигезендә рациональ урнаштыру;

куркыныч янаган чорда комплекслы маскировка чараларын планлаштыру һәм үткәрү;

энергия һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганаклары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сугыш вакытында эшен дәвам итә торган икътисад объектларында һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм уздыру;

җитештерү процессын торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан булдыру;

документациянең иминият фондын булдыру;

заманча зарарлану чаралары тәэсирендә җитештерү фондларын яклауның нәтиҗәлелеген арттыру. Күрсәтелгән чараларны үтәүне оештыру Азнакай муниципаль районы территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклылыгын арттыру комиссиясенә һәм оешмага йөкләнә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча http://aznakaevo.tatar.ru.урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Шәмсетдинов